Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № II-1**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 10 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 22 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында» I-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 48 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 22 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында» I-3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пункттагы «Леонов Владимир Александровичны - Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрын - конкурс комиссиясе рәисе итеп (килешенү буенча)» сүзләрен «Фәхретдинов Альберт Шамил улын - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Кулон» ябык акционер җәмгыяте генераль директорын - конкурс комиссиясе рәисе итеп (килешенү буенча)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев